МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ
ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.05.2024 Казан шәһәре № 144/2-пр

Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе утырышын уздыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм хәбәрнамәләрнең керү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указы белән расланган Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында нигезләмәнең 16 пунктындагы «б» пунктчасы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 25 августындагы 569-ПУ номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турында» 2023 елның 13 октябрендәге 384/2-пр боерыгы белән расланган Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турында нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә **б о е р а м:**

1. Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе утырышын уздыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм хәбәрнамәләрнең керү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге боерыкның үтәлешен үзем тикшереп торам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр М.А. Җәббаров

Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының
2024 елның 28 маендагы
144/2-пр номерлы боерыгы
белән расланды

**Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе утырышын уздыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм хәбәрнамәләрнең керү ТӘРТИБЕ**

1. Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе утырышын уздыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм хәбәрнамәләрнең керү тәртибе (алга таба - Тәртип) Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба - Министрлык) кадрлар бүлегенә түбәндәгеләрнең керү процедурасын билгели:

Министрлыкта вазыйфа биләгәндә дәүләт хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының Министрлык боерыгы белән расланган исемлегенә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче гражданның коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада хезмәт шартнамәсе шартларында вазыйфа биләүгә йә коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокук шартнамәсе шартларында эшләр башкаруга ризалык бирүе турында мөрәҗәгате - әгәр дәүләт хезмәтеннән азат ителгән көннән ике ел узганчы әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычлары составына кергән булса;

Министрлыкта дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба - дәүләт хезмәткәрләре) объектив сәбәпләр аркасында хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү мөмкинлеге булмау турындагы гаризалары;

Министрлыкта дәүләт хезмәткәрләренең «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмау турында гаризалары - чит ил банкында счетлары (кертемнәре) булган, акчалары һәм кыйммәтле әйберләре саклана торган һәм (яисә) чит ил

финанс инструментлары булган дәүләт хезмәткәрләре шул ил законнары нигезендә аның компетентлы органнары тарафыннан кулга алынуга, эш итүләре тыелуга яисә аларның ихтыярына яки хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка шартларга бәйле рәвештә.

Министрлыкта дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәрнамәсе керү һәм аны карау тәртибе Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында» 2016 елның 19 февралендәге 18/2-пр номерлы боерыгы белән җайга салына.

2. Гражданның әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләре, дәүләт хезмәткәренең гаризалары (алга таба – мөрәҗәгать (гариза) әлеге Тәртипкә 1-3 нче кушымталарда китерелгән формалар буенча язма рәвештә рәсмиләштерелә һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарына – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрына (алга таба – министр) (аның вазыйфаларын башкаручы затка) Министрлыкның эш алып бару бүлеге аша җибәрелә.

Мөрәҗәгатькә (гаризага) гражданның, дәүләт хезмәткәренең мөрәҗәгатьтә (гаризада) бәян ителгән шартларны, дәлилләрне һәм фактларны раслый торган өстәмә материаллары өстәлеп бирелергә мөмкин.

3. Кергән мөрәҗәгать (гариза) кабул ителгән көнне Министрлыкта билгеләнгән эш алып бару кагыйдәләре нигезендә теркәлә.

4. Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) мөрәҗәгать (гариза) кергән көннән өч эш көне эчендә аны Министрлыкның кадрлар бүлегенә алдан карау өчен җибәрә.

5. Мөрәҗәгатьне (гаризаны) алдан карау нәтиҗәләре буенча коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат (алга таба – җаваплы зат) язма рәвештә дәлилле бәяләмә әзерли.

Дәлилле бәяләмә әзерләгәндә җаваплы зат мөрәҗәгать (гариза) биргән дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә уздырырга, аннан язма аңлатмалар алырга хокуклы.

Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча дәлилле бәяләмә әзерләгәндә, министр яки аның шуңа махсус вәкаләтле урынбасары билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга гарызнамәләр җибәрә ала, коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә «Посейдон» дәүләт мәгълүмат системасын куллана ала, шул исәптән гарызнамәләр җибәрү өчен дә.

6. Мөрәҗәгать (гариза), аңа өстәлгән материаллар, дәүләт граждан хезмәткәреннән алынган язма аңлатмалар (булган очракта), шулай ук мөрәҗәгатьне (гаризаны) алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилле бәяләмә җаваплы зат тарафыннан мөрәҗәгать (гариза) кадрлар бүлегенә кергән көннән җиде эш көне эчендә Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең

хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе (алга таба – Комиссия) рәисенә тапшырыла.

Әлеге Тәртипнең 5 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән гарызнамәләр җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать, бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия рәисенә хәбәрнамә кадрлар бүлегенә кергән көннән 45 көн эчендә тапшырыла. Билгеләнгән срок озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән артыкка түгел.

7. Комиссия мөрәҗәгатьне (гаризаны), дәлилле бәяләмәне һәм башка материалларны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турында» 2023 елның 13 октябрендәге 384/2-пр боерыгы белән расланган Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турында нигезләмәдә каралган тәртиптә һәм срокларда карый.

Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе утырышын уздыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм хәбәрнамәләрнең керү тәртибенә
1 нче кушымта

**форма**

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры

(кемгә)________________________________

(кемнән)______________________________
______________________________________
(Ф.И.Ат.ис. (*соңгысы – булса*), вазыйфасы, телефон номеры)

**Коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада хезмәт шартнамәсе шартларында вазыйфа биләүгә йә коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокук шартнамәсе шартларында эшләр башкаруга ризалык бирү турында**
**МӨРӘҖӘГАТЬ**

Мин,_______________________________________________________________
(фамилия, исем, атасы ис. (булса), туган көне, яшәү урыны адресы)
______________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында _____________ елның _____________алып ___________ елның _____________кадәр түбәндәге дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүче,
______________________________________________________________________,
(вазыйфа исеме)
«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы нигезендә түбәндәгеләргә ризалык бирүне сорыйм:

- вазыйфа биләүгә

______________________________________________________________________
(граждан планлаштыра торган вазыйфаның исеме)
йә
- граждан-хокук шартнамәсе шартларында эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә)

(граждан башкарачак эшләрнең төрләре, хезмәт күрсәтүләрнең исемнәре)

(коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешманың исеме)

(коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешманың урнашкан урыны)

(коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешманың эшчәнлек үзенчәлеге)

дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә мин бу оешмага карата түбәндәге дәүләт идарәсе функцияләрен<*> башкардым:

(нindиләр икәнен күрсәтергә)

Минем вазыйфаи бурычларыма (башкара торган эшләремә) түбәндәгеләр керәчәк:

(граждан-хокук шартнамәсе төзелгән очракта, вазыйфаи бурычларның кыскача тасвирламасы, башкара торган эшнең үзенчәлеге)

Хезмәт яисә граждан-хокук шартнамәсенең каралган гамәли срогы ____________________

Хезмәт яисә граждан-хокук шартнамәсе буенча эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) өчен каралган түләү суммасы ____________________

Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе утырышында әлеге мөрәҗәгатьне караганда шәхсән үзем катнашырга телим /катнашырга теләмим *(астына сызарга)*.

Кабул ителгән карар турында мәгълүматны түбәндәгечә җибәрүегезне сорыйм:

(җибәрү ысулы күрсәтелә (почта аша, электрон рәвештә, кулга тапшыру һ.б.)

(әгәр почта аша яисә электрон рәвештә җибәрү ысулы күрсәтелсә, почта адресы яки электрон почта адресы күрсәтелә)

(дата) (имза) (имзаның ачыкламасы)

--------------------------------

<*> оешмага дәүләти, муниципаль (административ) идарә итү функцияләре – дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрнең бу оешмага карата кадрлар, оештыру-техник, финанс, матди-техник яисә башка мәсьәләләр буенча, шул исәптән бу оешманың аерым төр эшчәнлеген һәм (яисә) аерым гамәлләрне башкаруга рөхсәтләр (лицензияләр) бирүгә бәйле мәсьәләләр буенча катгый үтәлергә тиешле карарлар кабул итү йә шундый карарлар проектларын әзерләү вәкаләтләре («Коррупциягә каршы көрәш турында» 2018 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы).

Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе утырышын уздыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм хәбәрнамәләрнең керү тәртибенә
2 нче кушымта

**форма**

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры

(кемгә)________________________________

(кемнән)________________________________
________________________________________
(Ф.И.Ат.ис. (*соңгысы – булса*), вазыйфасы, телефон номеры)

**Объектив сәбәпләр аркасында хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү мөмкинлеге булмау турында**
**ГАРИЗА**

Мин хатынымның (иремнең) һәм балигъ булмаган балаларымның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр итәм
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(хатынның (ирнең) һәм (яисә) балигъ булмаган балаларның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), балигъ булмаган балаларның туган көне)

_____________________________________________________________________________,
бу түбәндәгеләргә бәйле:
______________________________________________________________________________
(Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе белешмәләрнең тапшырылмавы объектив һәм мөһим үзенчәлеккә ия дигән нәтиҗә ясый алсын өчен кирәкле барлык сәбәпләр һәм шартлар күрсәтелә)

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Гаризага түбәндәге материалларны өстәп бирәм (булса):

______________________________________________________________________

(өстәп бирелә торган материаллар күрсәтелә)

Күрсәтелгән белешмәләрне тапшыру буенча дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан күрелгән чаралар:______________________________________________________________

______________________________________________________________________

Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе утырышында әлеге гаризаны караганда шәхсән үзем катнашырга телим /катнашырга теләмим *(астына сызарга)*.

_______________ _____________________ ______________________________

(дата) (имза) (имзаның ачыкламасы)

Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе утырышын уздыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм хәбәрнамәләрнең керү тәртибенә
3 нче кушымта

**форма**

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры

(кемгә)_______________________________

(кемнән)______________________________

______________________________________

(Ф.И.Ат.ис. (*соңгысы – булса*), вазыйфасы, телефон номеры)

**«Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмау турында**

**ГАРИЗА**

Мин «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба - Федераль закон) 3 статьясындагы 1 өлеше, 4 статьясындагы 3 өлеше таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмау турында хәбәр итәм - бу чит ил территориясе банкында счетлар (кертемнәр) булган, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклана торган һәм (яисә) чит ил финанс инструментлары булган шул дәүләт законнары нигезендә әлеге илнең компетентлы органнары тарафыннан кулга алынуга, эш итү тыелуга яисә үземнең ихтыярыма яки хатынымның (иремнең) һәм балигъ булмаган балаларымның ихтыярына бәйле булмаган түбәндәге башка шартларга бәйле:

____________________________________________________________________________

(Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе Федераль законның күрсәтелгән таләпләрен үтәмәүнең сәбәбе объектив һәм мөһим үзенчәлеккә ия дигән нәтиҗә ясый алсын өчен кирәкле барлык сәбәпләр һәм шартлар күрсәтелә)

____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Гаризага түбәндәге материалларны өстәп бирәм (булса):
______________________________________________________________________

________________________________________________________________
(өстәп бирелә торган материаллар күрсәтелә)
__________________________________________________________________________

Федераль законның күрсәтелгән таләпләрен үтәү өчен күрелгән чаралар:
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе утырышында әлеге гаризаны караганда шәхсән үзем катнашырга телим /катнашырга теләмим *(астына сызарга)*.

______________ ____________________ _______________________________
(дата) (имза) (имзаның ачыкламасы)